# КАРАР

16 декабрь, 2024 ел №2

Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Аман-Оштырма авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 16 декабрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:
«Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Березняк авыл җирлеге Аман-Оштырма авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге баласын тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- **традицион күмү урыннарын төзекләндерү, коймалар кору, ремонтлау** (зират территориясен карап тоту һәм төзекләндерү, агачларны кисү һәм тураклау, эш кораллары һәм инвентарь сатып алу, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

- **җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү** (Аман-Оштырма авылы чишмәсе территориясен төзекләндерү, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материаллар сатып алу, чишмә территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

- **торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм җәяүлеләр** күперләрен төзү, ремонтлау, карап тоту (Аман-Оштырма авылында урам-юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре); (юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, җәяүлеләр күперен төзү, проект-смета документлары һәм

техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

**- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү** (янгын гидранты һәм комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру һәм карап тоту буенча башка эш төрләре)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 64 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 38 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 35 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Аман-Оштырма авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Березняк авыл җирлеге Аман-Оштырма авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, үзара салым суммасының 100 % ы күләмендә ташлама билгеләнгән 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрбиләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

**- традицион күмү урыннарын төзекләндерү, коймалар кору, ремонтлау** (зират территориясен карап тоту һәм төзекләндерү, агачларны кисү һәм тураклау, эш кораллары һәм инвентарь сатып алу, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- **җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү** (Аман-Оштырма авылы чишмәсе территориясен төзекләндерү, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материаллар сатып алу, чишмә территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

- **торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм җәяүлеләр** күперләрен төзү, ремонтлау, карап тоту (Аман-Оштырма авылында урам-юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре); (юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, җәяүлеләр күперен төзү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- **янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү** (янгын гидранты һәм комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру һәм карап тоту буенча башка эш төрләре)

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Березняк авыл җирлеге
башлыгы Р.Ф. Шәрипов